ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ОТАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОТАРКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул.Октябрьская, д.17, с. Отарка,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422180

Октябрь ур., 17 нче йорт, Отарка авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422180

тел.(факс): (85563) 4-05-07; e-mail: Otar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление
от 20.02. 2023 ел

Карар
№17

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге башкарма комитетының 2014 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге халык дружинасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 76 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» 2014 елның 2 апрелендәге N 44-ФЗ Россия Федерациясе Федераль законына, «Җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (үзләштерүгә) каршы тору һәм терроризмны финанслау турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 28 июнендәге № 219-ФЗ Федераль законына, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге башкарма комитетының 2014 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге халык дружинасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 76 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 3 бүлегендәге 1 пунктының 4 пунктчасына «яисә террорчылык оешмалары һәм террорчылар яки күпләп юк итү коралы таратуга катнашы булган оешмалар һәм физик затлар исемлегенә кертелгән, яисә БМО Уставының VII бүлеге, БМОның Куркынычсызлык Советы яисә БМО Куркынычсызлык советының махсус төзелгән карарлары белән каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында» сүзләрен өстәргә.

1.2. 1 нче кушымтаның 2 бүлегендәге 5 пунктының 4 пунктчасына «яисә террорчылык оешмалары һәм террорчылар яки күпләп юк итү коралы таратуга катнашы булган оешмалар һәм физик затлар исемлегенә кертелгән, яисә БМО

Уставының VII бүлеге, БМОның Куркынычсызлык Советы яисә БМО Куркынычсызлык советының махсус төзелгән карарлары белән каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында» сүзләрен өстәргә.;

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Отарка авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе / И.И.Фазылов/